КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 апрель г.Казань № 265

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче; 2024 ел, 23 март, 177 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «һәм Россия Федерациясе дәүләт программалары порталында (www.programs.gov.ru)» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары акчасы белән бүтән баш эш итүчеләргә түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы дәүләт программаларын үтәү өчен җаваплы территориаль органнарына – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

2024 елның 13 маена кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы

турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турындагы нигезләмә буенча эшләнгән 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау турында, Татарстан Республикасы дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне тәэмин итүне;

2024 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турындагы нигезләмә буенча 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыру кысаларында дәүләт программалары белән идарә итүнең цифрлы модулендә дәүләт программасы паспортына һәм аның структур элементларына үзгәрешләр кертүне тәэмин итүне.

3. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин